Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы

КАРАР

2021 елның 3 ноябреннән № 6

Аксубай муниципаль районы Яна Аксубай авыл җирлегенең Кече Аксубай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнарҗыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы Яна Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә **КАРАР БИРӘМ:**

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлеге Кече Аксубай торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2021 елның 16 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
2022 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яна Аксубай авыл җирлеге Кече Аксубай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзсалым кертергә.

1. **Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:**

   - су белән тәэмин итү өчен насос сатып алу.

2. **ККкНЫ җыю ( шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**

- контейнер мәйданчыклары төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Аксубай районының Кече Аксубай авылының Лесная урамы 11 нче йорт адресы буенча урнашкан йорт янында гражданнар җыенын үткәрергә.

4.Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм такталарда игъланнар такталарында элү юлы белән, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы
Аксубай муниципаль районы А.В.Макаров